КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 25 ноябрь г.Казань № 1131

Муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗади коллективлары проектларына ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турындагы нигезләмәне, муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗади коллективлары проектларына ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын алучыларны билгеләү советы составын, муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗади коллективлары проектларына ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын түләү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗади коллективлары проектларына ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турындагы нигезләмәне (алга таба – Нигезләмә);

муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗадит коллективлары проектларына ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын алучыларны билгеләү советы составын;

Муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗади коллективлары проектларына ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын түләү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен.

2. Бу карар (Нигезләмәнең 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 6.4 пунктыннан тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин